РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.01.2019 № 71-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районында җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2010 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 февраленнән Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче Кушымта һәм 2 нче Кушымта нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында” 2018 елның 31 гыйнварындагы 82-п номерлы карары 2019 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны “Саба таңнары” район газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Кушымта №1
Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
30.01.2019 ел № 71-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2706,49 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып кайту | 539,44 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,54 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Кушымта №2
Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
30.01.2019 ел № 71-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәнне кәфенләү | 236,62 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2469,87 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып кайту | 539,44 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,54 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |